**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«16» 02 2023 ел №529

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты белән килешү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Тукай муниципаль районы уставына, Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча 2023 елның 8 февралендәге халык тыңлаулар беркетмәсенә, Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча 2023 елның 8 февралендәге халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәгә таянып

**КАРАР БИРӘ**

1. «КонТраст» ЖЧҖ тарафыннан эшләнгән һәм 2023 елның 8 февралендәге Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында халык тыңлауларында каралган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты белән килешергә.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын халык тыңлаулар беркетмәсе һәм халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә белән Тукай муниципаль районы Советына раслауга җибәрергә.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1639031830